# МУСА ҖӘЛИЛ ӘСӘРЛӘРЕН РУС ҺӘМ ИНГЛИЗ ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Әхмәдгалиева Г.Г.,*

*Казан федераль университеты, Алабуга институты*

Татар телендә иң катлаулы һәм авыр иҗат төрләрнең берсе булып – матур әдәбият әсәрләрен тәрҗемә итү санала. Утыз ел дәвамында француз әдәбиятыннан төрек теленә роман-хикәяләр тәрҗемә иткән төрек әдибе Җәмил Мәрич әдәби тәрҗемә турында болай дип яза: «Тәрҗемә ул – яралту, минемчә, шигырь кебек, нәсер кебек, хәтта алардан да кыенрак. Тәрҗемә әдәби жанрлар арасында иң авыры – башка җирлектә һәм башка чорда туган уй-фикерне үз җиреңдә терелтү. Тәрҗемә – яулау, яулау гына түгел, уй һәм хисләрнең катлаулы дөньясын баетучы казаныш ул».

Безнеңчә, матур әдәбиятны тәрҗемә итүче бер үк вакытта көзге ролен дә башкара. Аның төп эше – әдип әсәрен чын мәгънәсендә түкми-чәчми башка халыкларга җиткерү. Тәрҗемәчеләр ярдәмендә, чит илләрдә яшәгән меңләгән башка милләт кешеләре, татар теленең әдәбият җимешләре белән таныша ала.

Ике телне белмичә, фәкать сүзгә-сүз тәрҗемәләр белән эш итүче шагыйрьләр еш кына шигырь эчтәлеген ярлыландыралар. Алар формаль рәвештә генә шигырь юллары, сүз иҗекләре санын сакларга тырышалар. Ягъни тышкы, формаль тәңгәллеккә омтыла. Андый тәрҗемәләрдә еш кына шагыйрьнең укучысына әйтәсе, җиткерәсе фикере нык гадиләштерелә.

Безгә якын дәвердә яшәп иҗат иткән классик әдип һәм шагыйрьләребезнең мирасын һәм исемнәрен дөнья мәйданына чыгару эше, кызганычка каршы, әлегә бик әкрен бара.

Поэзия тәрҗемәсенең үзенчәлекләре шигырьнең жанр табигатенә бәйле. Шигырьдә сүз яңа мәгънә төсмерләре, эмоциональ чынбарлык ала. Сүзләр тәртибе дә башкача була. Шигырьгә ритмик формадан тыш, аерым синтаксис хас. Бер яктан, ритм, рифма, строфаны гәүдәләндерү, икенче яктан, сүзне бирү таләбе, кайчак, проза тәрҗемәсенә караганда кискенрәк

була: еш кына теге яки бу сүз яисә сүзтезмә шигырьгә «сыймый» яки аны, киресенчә, тутырып бетерми. Шунлыктан ритм, рифма таләпләренә җавап бирә торган сүзләр сайлау таләп ителә. Менә шуңа күрә дә сүзгә-сүз төгәллек карашыннан чыгып эш иткәндә, шигырь тәрҗемәләре, кагыйдә буларак, проза тәрҗемәләренә караганда, оригиналдан һәрвакыт ераграк була. Ритм-рифма закончалыклары мәгънәви һәм лексик адекватлыкка ирешүдә кыенлыклар китереп чыгара, нәтиҗәдә шигъри әсәрләрдә тәрҗемә белән оригинал арасында аерма килеп чыга.

Шунысы кызыклы: күп очракта бер үк поэзия әсәрләре төрле кешеләр тарафыннан кат-кат тәрҗемә ителә. Поэзияне тәрҗемә итү белән, гадәттә, шагыйрьләр шөгыльләнә һәм алар еш кына тәрҗемә әсәрләрен үз җыентыкларына кертәләр. Бер үк шигырьнең тәрҗемәләре арасындагы аерма бер үк проза әсәрләре арасындагы аермадан шактый зур була.

Шигъри тәрҗемәнең түбәндәге төрләре билгеле:

*Стильгә салынган тәрҗемә* – тәрҗемәнең ирекле төре, гомуми мәгънә, эчтәлек саклана, ләкин төзелеше, формасы буенча оригиналыннан шактый ерак. Бу тәрҗемә төре шактый сирәк кулланыла.

*Букваль тәрҗемә* – оригиналга ияреп тәрҗемә итү, сәнгатьчә эшләнеше, шигъри калып югалырга мөмкин. Бу тәрҗемә икенче төрле «*подстрочный перевод*» дип тә атала.

*Функциональ тәрҗемә* – тәңгәллекләр сайлауга нигезләнә, текст оригиналга яраклаштырып эшләнә. Бу төр тәрҗемә киң таралган.

*Әдәби тәрҗемә* – оргиналга ияреп тәрҗемә итү, шул ук вакытта тәрҗемә теле үзенчәлекләренә яраклаштырып эшләнә. Төп максат булып шигырнең стилен мөмкин кадәр саклау.

*Формаль тәрҗемә* – кирәкле рифма һәм әйләнмәләр сайлап алып, сүзгә сүз тәрҗемә итү. Бу төр тәрҗемә иң идеаль санала.

Күренгәнчә, шигъри тәрҗемәдә төп авырлык тәрҗемәнең шигъри структурасы белән бәйле. Эш шунда: тәрҗемә иткән вакытта, тәрҗемә оригиналдан аерылырга мөмкин. Тәрҗемәче тәрҗемә итә башлагач, иң

беренче булып шуны истә тотарга тиеш: шигырь юллары оригиналга якын килерме яисә юкмы. Беренче очрак авыр, ләкин иң кулае. Әгәр тәрҗемәче шигырьнең структурасын үзгәртергә тели икән, аңа нинди структура әйбәт икәнлекне ачыкларга кирәк. Бу вакытта шулай ук шигырьнең мәгънәви яктан тулыландыру турында да уйларга кирәк. Әсәрнең тышкы формасы, аның мәгънәсенә туры килергә тиеш. Кайбер очракларда татар теленнән рус теленә тәрҗемә иткәндә юлларда строфалар санын арттыру мөһим.

Билгеле, «Моабит дәфтәрләре» – Муса Җәлил шигъриятенең иң югары ноктасы булып санала. Бу шигырьләрендә шагыйрьнең шәхси образы, кичерешләре, фәлсәфи уйланулары аша кеше рухының бөеклеге, гуманистик табигате, гаделлек һәм хаклык тантанасына тирән ышанычы, туган халкына чиксез мәхәббәте гаҗәеп тәэсирле, эмоциональ көч һәм сәнгатьчә камиллек белән гәүдәләнә.

Мәгълүм булганча, М.Җәлил әсәрләре бүгенге көндә илле дүрт телдә басылып чыккан. Тәрҗемәләренең кат-кат эшләнүе, андый җаваплы эшкә илебезнең иң тәҗрибәле тәрҗемәчеләренең җәлеп ителүе нәтиҗәсендә аларның сыйфаты да канәгатьләнерлек. Бу фикергә без “Моабит дәфтәрләре” циклына кергән кайбер шигырьләрнең рус һәм инглиз теленә тәрҗемәләрен чагыштырып, мәгънә тәңгәллеген, эчтәлекнең бирелешен, стилистикасын тикшереп караганнан соң килдек. Мисалларны карап үтик. Мәсәлән:

*Еллар буе, бәлки, хатым булмас,*
*Хәбәр булмас минем турымда.*

(“Сөеклемә”)

*Годами, может быть, письма не будет,*
*Ни весточки, ни слуха не дойдет.*

(*“*Любимой*”Перевод С.Северцева*)

*Perhaps the years go by, no letters come,*
*Or any news of me.*

(«To my love» *Translated by Gladys Evans*)

Күргәнебезчә, бу шигъри тәрҗемә, *әдәби тәрҗемә* төренә якын, оригиналга ияреп тәрҗемә ителгән, шул ук вакытта тәрҗемә теле үзенчәлекләренә яраклаштырып эшләнгән. Шигырнең стиле мөмкин кадәр сакланган. Сүзләр рус һәм инглиз теленә эквивалент сүзләр ярдамендә тәрҗемә ителгән: *еллар – года – years; хат – письмо – letter.* Тик, игътибар итсәк, *булмас* сүзе рус теленә төгәл тәрҗемә ителгән (*не будет*), ә инглиз телендә тәрҗемә семантик яктан бераз аерыла (*no come*). Шулай ук, оригиналда *бәлки – perhaps* сүзе юк, ә тәрҗемәче Г.Эванс аны кирәк дип санап, шигырьгә кертеп җибәрә. Тәрҗемәләрнең ритм-рифма ягына игътибар итсәк, оригиналда бирелгән юллардагы сагыш, моң тәрҗемәләрдә бирелеп бетмәгән кебек тоела.

Тагын бер мисалны карап үтик:

*Мин чикмәдем, дускай, бер карыш та,*

*Батырларча алга атладым.*

(“Яулык”)

*Перед врагом колен не преклонял я.*

*Не отступил в сраженьях ни на пядь.*

(«Платочек», *Перевод В. Ганиева*)

*I've not given an inch of my land,*

*To the foe I have never knelt.*

(«The shawl», Translated by Dmitry Priyatkin)

Бу очракта исә, күз алдыбызда *стильгә салынган тәрҗемә* төре – ирекле, гомуми мәгънә, эчтәлек саклана, ләкин төзелеше, формасы буенча оргиналыннан шактый ерак. Күргәнебезчә, монда гомуми мәгънә генә сакланган, тәрҗемә тасвирлама характерда бирелгән.

Күргәнебезчә, шигырь тәрҗемәсе – катлаулы эш, төп авырлык тәрҗемәнең шигъри структурасы белән бәйле. Шигъри сүз – җөмләне башка телгә зур төгәллек белән күчерү осталары бик сирәк очрый. Ике телне белмичә, фәкать сүзгә-сүз тәрҗемәләр белән эш итүче шагыйрьләр еш кына шигырь эчтәлеген ярлыландыралар. Тәрҗемәче шигырьне тәрҗемә иткән

вакытта бер яктан, ритм, рифма, строфа, икенче яктан, лексика таләпләренә җавап бирерлек тел чараларын сайлап ала белергә тиеш. Шигырьне тәрҗемә итүдә кайсы төргә нигезләнү, нинди алымнар куллану – барысы да тәрҗемәченең таланты һәм осталыгыннан тора. Һәм иң мөһиме – укучы тәрҗемә текстын укыган кебек түгел, ә авторның оригинал текстын укыган итеп тоелсын иде.

Әдәбият исемлеге:


1. Камаева Р.Б. Матур әдәбият тәрҗемәсе. – Казан: "Школа" редакция-нәшрият үзәге, 2015. – 136 б.
2. Салимова Д.А., Тимерханов А.А. Двуязычие и перевод: теория и опыт исследования. Монография. – М.:Флинта: Наука, 2012. – 280 с.
3. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. – Казань: Ихлас, 2012. – 91 б.